**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында» 2022 елның 12 апрелендәге ПУ-266 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 апрелендәге 256 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында нигезләмәгә, 5 пунктта «идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салуны) башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 21 май
№ 375